РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

Ленин ур.-14 нче йорт, Азнакай ш., 423330

Тел./факс(885592)7-15-50, 7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru кат adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 март 2002 ел № 09

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендәге 86-24 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү хакында (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33, 22.10.2019 №149-36, 12.03.2020 №165-41 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Азнакай шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә карар бирәм:

1. Азнакай шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 86-24 номерлы карары (карарлар редакциясендә) белән расланган Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны әзерләүгә керешергә (24.11.2014 №146-41, 25.08.2015 №174-48, 17.03.2016 №20-5, 25.08.2016 №32-8, 09.12.2016 №38-11, 29.09.2017 №56-18, 22.08.2018 №108-27, 13.12.2018 №121-29, 23.05.2019 №136-33, 22.10.2019 №149-36, 12.03.2020 №165-41 карарлар редакциясендә):

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында:

- Азнакай ш., а. Вәлиханов ур., 5А йорт адресы буенча урнашкан 16:44:01028:167 кадастр номеры булган җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны эшлекле, иҗтимагый һәм коммерцияле билгеләнештәге Д1-Д1-индивидуаль торак йортлар төзү зонасына үзгәртергә.

- Азнакай ш., Әлмәт тракты ур., 20В й. адресы буенча урнашкан 957 кв. м мәйданлы 16:44:0000:487 кадастр номеры булган җир кишәрлеге өчен

территориаль зонаны П4 классы җитештерү-коммуналь объектлар зонасыннан Ж1 шәхси торак йортлар төзү зонасына үзгәртергә.

2. Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү тәртибен һәм вакытларын билгеләү (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М. И. Солтанов

1 нче кушымта
Азнакай муниципаль районы Башкарма
комитеты карары буенча
№ 2020 ел.

**Азнакай муниципаль районының “Азнакай шәһәре” муниципаль берәмлек җирләреннән файдалану һәм төзелеш эшләре кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү һәм әзерләү эшләрен үткәрү тәртип һәм сроклары**

| N | Азнакай муниципаль районы "Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Азнакай шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2020 елның I-II кварталы. |
| 2.<br>2.1.<br>2.2. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә һәм картографик материалларга үзгәрешләр кертү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволар кисәтүләренә шәрехләр әзерләү. | 2020 елның I-II кварталы. |
| 3.<br>3.1.3.2.<br>3.3.3.4. | Азнакай шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча фикер алышу<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында закон проектына үзгәрешләр кертү.<br>Күрсәтелгән проектны һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) Башкарма комитет җитәкчесенә тапшыру.<br>Азнакай муниципаль районы башлыгына әлеге проектны шәһәр Советына раслауга яки кире кагуга кертү һәм аны кабат тапшыру датасын күрсәтеп, эшләп бетерергә җибәрү турында Карар кабул итү өчен Азнакай шәһәренең Җир биләмәләреннән файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект җибәрү. | 2020 елның II кварталы. |